# Татарстан

**Татарстан – туган җирем,**
**Уртасында – Иделем,**
**Фонтаннары - кара алтын,**
**Сары алтын – игенем.**

***Нәкый Исәнбәт***

# Ватаным-Татарстан




Татарстан- безнең Ватаныбыз.
Ул Татарстан Республикасы дип атала.
Аның гербы, флагы һәм гимны бар.



Татарстанның башкаласы - Казан шәһәре.
1920 нче елның 27 маенда ТАССР төзелә.
1990 нчы елның 30 нчы августы - ТР көне.



**Флагның авторы-Тавил Хаҗиәхмәтов. Флаг 1991 нче елның 29 ноябрендә кабул ителде.**




**Гербның авторы – Риф Фәхретдинов. Герб 1992 нче елның 7 февралендә кабул ителде.**

**Татарстан Республикасының гимнын композитор Рөстәм Яхин язган. Гимн 1993 елның 14 июлендә кабул ителде.**

Татарстан Республикасы гимны.

1. Күпме юллар йөрдем, дөнья күрдем
   Назлы җилләр йөзем сыйпады.
   Сиңа кайткач кына, туган ягым,
   Күкрәгемә шатлык сыймады.
2. Тик бер генә көнгә аерылсам да
   Ямансулап сине юксынам.
   Синнән башка миңа, туган ягым,
   Бу дөньяда тормыш юк сыман.
3. Тик бер генә көнгә аерылсам да
   Ятим калган кебек буламын
   Тик син генә яшәү матурлыгы,
   Гүзәллеге якты дөньяның

# Татарстанның президенты Р.Н.Миңнеханов




Татарстанда татарлар, руслар, марилар, чувашлар, удмуртлар һәм башка милләтләр дус яши.Татарстанда татар һәм рус телләре дәүләт телләре булып тора.






# Кроссворд чишү



# Кроссворд чишү

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Н | | | | | | |
| Ә | | О | | А | | | Б | К |
| Л | | К | | К | | Н | А | А |
| М | | Р | | Б | | Е | У | З |
| Ә | | А | К | А | | Ф | М | А |
| Т | А | Т | А | Р | С | Т | А | Н |
| | Р | | М | С | А | Ь | Н | |
| | Ч | | А | | Б | | | |
| | А | | З | | А | | | |

Кроссворд




1. Татарстан урманнарында яшәүче кыргый җәнлек һәм Казан күленең исеме.
2. Казандагы атаклы татар театры.
3. Татарстанда чыга торган йөк машиналары.
4. Татарстанның хоккей командасы.
5. Казанның бердәнбер җәяүлеләр урамы.

# Татарстан

Мин яратам сине, Татарстан,
Ал таңнарың өчен яратам,
Күк күкерәп, яшен яшьнәп яуган
Яңгырларың өчен яратам.

Мин яратам сине, Татарстан.
Горур халкың өчен яратам,
Җан эреткән әнкәм телең өчен,
Татар телең өчен яратам;

Адаштырган урманнарың өчен,
Тугайларың өчен яратам,
Тукайларың, Сәйдәшләрең өчен,
Җәлилләрең өчен яратам.
Татарстан, сине яратам.